**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**Утыз тугызынчы утырыш тугызынчы чакырылыш**

29 июль 2024 ел №110 Кече Кибәхуҗа ав.

**Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 08.06.2009 № 8 «Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең персональ күрсәткечләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 08.06.2009 № 8 «Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең персональ күрсәткечләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына (12.03.2021ел №14, 10.03.2022 ел №42, 16.01.2023ел №71 карарлар редакциясендә),түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган, Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең персональ күрсәткечләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәгә:

а) 2.5 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;

б) 2.6 пунктта «Белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетада булган белешмәләрдән тыш)» сүзләре белән тулыландырыга

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башлыгы: И.Г.Заһидуллин